**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

« 04 » 03 2019 ел Яр Чаллы №759

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче авыл җирлекләре территориясендә урнашкан каты көнкүреш калдыкларын туплау урыннары (мәйданнары) реестрын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру турында» 131-ФЗ санлы Федераль законга таянып, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 89-ФЗ санлы Федераль законның 13.4 маддәсе 4 пункты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 августындагы «Каты көнкүреш калдыкларын туплау урыннарын (мәйданнарын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 1039 санлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче авыл җирлекләре территориясендә урнашкан каты көнкүреш калдыкларын туплау урыннары (мәйданнары) реестрын расларга (1,2,3 кушымталар).
2. Тукай муниципаль районы территориясендә каты көнкүреш калдыкларын туплау урыннарын (мәйданнарын) булдыруны килештерү турында гариза формасын расларга (4 кушымта).
3. Тукай муниципаль районы территориясендә каты көнкүреш калдыкларын туплау урыннары (мәйданнары) турында мәгълүматларны кертү өчен гариза формасын расларга (5 кушымта).
5. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республиксы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И.Х. Абзаловага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов